

Рузаевка районы Татар Пешлә авылы клубында, “Алтын куллар” (“Золотые руки”) твгәрәгендә катнашучылар бергә жыелып татар милли баш киеме - калфак тегәләр.
Бу твгәрәкне Оксана Владимировна Яшина житәкли. Анын житәкчелегендә твгәрәктә тегәләр, чигәләр һәм бәйлиләр. Эш шунда ки, vзенен матур концертлары белән Мордовиядән читтә дә билгеле булган Наталья Анатольевна Чалдаева житәкләгән Татар Пешләсе “Сандугачлар” ансамблена биш ел тулды. Шуна әзерлек вакытында, алар концерт костюмнарын да янартырга булганнар. “Алтын куллар” твгәрәгендә, Оксана Владимировна ярдәме белән Ниясова Шафика Шекур кызы, Чермантеева Халидә Хабибулла кызы, Шемалова Гелфира Рәстәм кызы, Толстякова Наилә Нияз кызы, Исянова Нурия Харис кызы безнен милли киемебез, халыкнын рухи байлыгынын бик моһим олеше булган калфакны, кvнел жылысын кушып, тегәләр. Хатын-кызларнын милли баш киеме булып саналган калфак классик этник костюм олеше генә твгел, милли мәдәният символы да. Еракларда калган, vткәннәргә кайтарган әлеге тарихи калфак һәркемнен кvнеленә хуш килә: тукыма сайлыйлар, кирәк булган лекало белән кисәләр, тырышып кул эшенә тотыналар. Житез оста куллар тиз арада калфак рәвешен китереп тә чыгаралар. Сәләтлеләр бар яктан да сәләтле, диләр. Чыннан да сәхнәдә дә алар беренче, кул эшләрендә дә. Дәлилгә алар турында социаль челтәрләрендә шундый свзләр дә бар:
- Татар Пешлә авылыбызда, регионыбызнын авылларындагы кебек vк, халык милли традицияләрен сак-лый. Безнен матур киемнәребез бар: кvлмәкләр, алъяпкычлар, камзул-жилетлар һ.б. Әмма, татар милли костюмы киемен тәмамлау очен, матур баш киеме булырга тиеш. Калфакны Пешлә клубында, жылы дуслык шартларында, “Алтын куллар” твгәрәгендә катнашучылар куллары белән ясала. Алар һонәрчелек белән кызыксыналар һәм буш вакытларын яраткан эшләрен зур рәхәтлек белән башкаралар!
Шунда тагы бер бәя бар. Сайтта Зульфия Гундина “Сандугачлар” ансамбле вәкилләре турында болай ди: “Сәләтле кешеләр бар яктан да сәләтле! Молодцы! Зур ихтирам белән сезгә!”
Калфак тегәргә теләvчеләр очен твбәндәге нәрсәләр кирәк булачак: уртача калынлыкта фетр, vзебез теләгән тостә тукыма, тегv кирәк-яраклары (жеп, энә, кайчы), декоратив ташлар яисә махсус бизәгечләр, жилем (суперклей). Эшне башкарганда фетрдан vзебезгә кирәк зурлыкта твгәрәк кисәбез. Твгәрәкне әйләндереп алырга житәрлек тасма кисәбез. Тасма белән твгәрәкне бер-берсенә тегеп чыгабыз. Килеп чыккан форманын кире ягын әйләндерәбез. Калфакнын остен капларлык тукыма кисеп алабыз. Тукыманы форма остенә тегеп чыгабыз. Артык кисәкләрен кисеп ташлыйбыз. Калфакны әйләндереп алырга житәрлек тасма кисәбез. Тасманы икегә бокләп, энә белән эләктереп чыгабыз. Тасманы тегеп чыгабыз. Аскы олештә калган тукыманы эчкә бокләп тегәбез. Калфакны бизибез. Монда фантазияга ирек бирергә кирәк. Язарга жинел булган эшне башкарып чыгар очен теләк, тырышлык кирәк. Тырышсагыз, сез дә калфак тегә аласыз.
Тагы бу твгәрәктә Яна ел бәйрәменә “Йолдыз” балалар ансамбле әгъза-ларына торле-торле костюмнар да тегәчәкләр.

Наилә НАСЫРОВА